**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасының М.И. Мәхмүтов исемендәге дәүләт премиясен бирү комитеты составына үзгәрешләр кертү турында**

Кайбер затларның башка эшкә күчүе белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының М.И. Мәхмүтов исемендәге дәүләт премиясен гамәлгә кую турында» 2017 елның 26 декабрендәге ПУ-1169 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасының М.И. Мәхмүтов исемендәге дәүләт премиясен бирү комитеты (алга таба – Комитет) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комитет составыннан Р.Р. Бәдриеваны, Ф.З. Мостафинаны, Ф.Ш. Мөхәммәтҗанованы, И.Г. Һадиуллинны чыгарырга;

б) Комитет составына кертергә:

Галиәкбәрова Әлфинур Азат кызын – Чаллы дәүләт педагоги университеты ректоры вазыйфаларын башкаручыны (килешү буенча);

Козлов Вадим Евгеньевичны – Педагогия, психология һәм социал мәсьәләләр институты директоры вазыйфаларын башкаручыны (килеш буенча);

Нагуманова Людмила Николаевнаны – Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты ректорын (килешү буенча);

Һидиятов Илнар Рүзәл улын – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Мәгариф идарәсе башлыгын (килешү буенча);

в) Комитет әгъзасы Л.Р. Фазлыеваның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2018 ел, 13 октябрь
№ ПУ-729